**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ИСКЕ ЧАЛЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

**«20» июнь 2024 ел** **№ 76**

**«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Чаллы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 17 июлендәге 105 номерлы Иске Чаллы авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25 - ФЗ номерлы федераль законнарга, «Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы һәм Россия Федерациясенең аерым закон актлары турында» Федераль законның 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 12 декабрендәге 594 номерлы Федераль законга, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Чаллы авыл җирлеге Советының 2019 елның 17 июлендәге 105 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Чаллы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә (2019 елның 25 октябрендәге 109 номерлы, 2019 елның 18 декабрендәге 2020 елның 21 февралендәге 120 номерлы, 2023 елның 23 августындагы 59 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән), түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 7нче бүлектә

7.4 пунктында

2нче пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« 2) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 15.2 статьясында каралган анкетаны;»

7нче бүлекнең 7.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.5) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль закон һәм муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы нигезендә граждан тарафыннан муниципаль хезмәткә кергәндә бирелгән мәгълүматлар (анкетада булган мәгълүматлардан тыш) федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә тикшерелергә мөмкин. Аерым муниципаль берәмлекләрдә федераль законнар белән муниципаль хезмәткә кергәндә граждан тарафыннан тапшырыла торган мәгълүматларны (анкетада булган мәгълүматлардан тыш) тикшерүгә өстәмә таләпләр билгеләнергә мөмкин.»;

9) 18нче бүлектә:

18.1 пунктын:

түбәндәге эчтәлектәге 12нче пункт белән тулыландырырга:

«12) "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" гы Федераль законның 15.2 статьясында каралган анкетадагы мәгълүматларның аңа билгеле булган үзгәрешләре турында яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) язма рәвештә хәбәр

итәргә, яллаучы (эш бирүче) вәкиле карары буенча үзгәртелгән мәгълүматлардан тыш (алга таба - анкетада булган мәгълүматлар).»

18.3 пунктында:

8нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм (яисә) ул үткән чорда ялган документлар һәм (яисә) муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә комачаулый торган чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәүне раслаучы, яисә муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә комачаулый торган чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәү турында документлар һәм (яисә) мәгълүматлар бирмәүче, муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә комачаулый торган чикләүләрне, тыюларны;»;

2. Әлеге карарны адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

Татарстан Республикасы, Нурлат муниципаль районы, Иске Чаллы авыл җирлеге, Иске Чаллы авылы, Ленин урамы, 6;

Татарстан Республикасы, Нурлат муниципаль районы, Иске Чаллы авыл җирлеге, Иске Чаллы авылы, Совет урамы, 40;

Татарстан Республикасы, Нурлат муниципаль районы, Иске Чаллы авыл җирлеге, Урта Чаллы авылы, Карл Маркс урамы, 12;

Татарстан Республикасы, Нурлат муниципаль районы, Иске Чаллы авыл җирлеге, Түбән Чаллы авылы, Ленин урамы, 3А йорты, әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында, шул исәптән Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Иске Чаллы авыл җирлеге Советы Рәисе И.Н. Захаров